ГЛАВА КАМАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

423643 с.Камаево, ул. Дифгата Сирая д.29А

423643, Камай авылы, Дифгать Сирай урамы, 29А йорты

Тел. (885549)3-55-33

2019 ел 14 нче ноябрь № 2

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Менделеевск муниципаль районы
Камай авыл җирлегенең Камай авылында
үзара салым кертү һәм куллану мәсьәләсе
буенча халык җыенын билгеләү турында

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Камай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлегенең Камай авылына үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын 2019 елның 30 нчы нояберенә 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлегенең Камай авылына үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын 2019 елның 30 нчы нояберенә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Җыенның барлык этапларын уздыру урыны итеп Камай авылының Дифгать Сирая урамы, 29а йорт адресы буенча урнашкан КФҮ (авыл мәдәният йорты)ны билгеләргә.

4. Җыен этапларына Камай авылында яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча түбәндәге тәртиптә җитештерергә:

Беренче этап:

Яшел урамы № 1 йорттан 25 йортка кадәр;

Тынычлык урамы 3 йорттан 24 йортка кадәр;

Дифгать Сирай урамы 1 йорттан 49 йортка кадәр.

Икенче этап:

Тынычлык урамы 25 йорттан 81 йортка кадәр;

25-нче номерлы йорттан 81-нче номерлы Тынычлык урамы, Сәйдәшев урамы 1-нче номерлы йорттан 18-нче номерлы йортка кадәр, Северная урамы 1-нче йорттан 16-нчы номерлы йортка кадәр

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

2020 елда Менделеевск муниципаль районының Камай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- видеокүзәтү сатып алу һәм урнаштыру;
- юлларны кардан чистарту;
- татар телендә урам күрсәткечләрен сатып алу һәм урнаштыру;
- янгын гидрантларын ремонтлау;
- янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру;
- генератор сатып алу;

«ӘЙЕ» «ЮК».

6. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Камай авыл җирлеге» бүлегендә кабул ителгән көннән алып 3 көн эчендә урнаштырырга.
7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Камай авыл җирлеге башлыгы: И.И.Әһлиева